таләпләрне куярга мөмкин. Бу очракта Закон сатучыны сыйфатсыз товарны кире кабул итәргә һәм кирәк булган очракта товарның сыйфатын тикшерергә мәҗбүр итә.

ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ! Житештерүче (башкаручы) тарафыннан гарантия срогын билгеләү аның бурычы түгел, ә хокукы булып тора.

Әгәр гарантия срогы билгеләнмәгән яисә инде ул чыккан булса (әмма сатып алганнан соң ике ел узмаган булса), кулланучы югарыда күрсәтелгән таләпләрнең берсен күрсәтү хокукыннан мәхрүм ителми. Аермалы буларак, җиһаздагы кимчелекләрнең җитештерүчедән булуын раслау авырлыгы кулланучы җилкәсенә ята. Ягъни, әгәр кулланучының сатучыга куелган таләпләре канәгатьләндерелмәсә, ул үз хисабына әлеге җиһазның сыйфатына карата экспертиза үткәрергә тиеш.

КУЛЛАНУЧЫНЫҢ ЭШ ИТҮ ТӘРТИБЕ

Югарыда күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерү өчен сатучыга ике нөсхәдә төзелгән язмача дәгъва һәм тәгәл формалаштырылган таләпләр белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Касса, товар чекларының һәм гарантия талонының күчермәләрен дәгъвага кушарга киңәш итәбез. Дәгъваның бер нөсхәсен сатучыга шәхсән тапшырырга кирәк (бу очракта сездә кала торган икенче нөсхәдә ул кабул итү турында билге куярга тиеш) яки почта аша, тапшыру турында уведомление белән, заказлы хат формасында җибәрергә кирәк.

Әгәр бәхәс судка кадәр тәртиптә җайга салынмаса, претензияне юллау белән, кулланучы үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен судка гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА БЕЛГЕЧЛӘРНЕҢ ТҮЛӘҮСЕЗ КОНСУЛЬТАЦИЯСЕН ТҮБӘНДӘГЕ ТЕЛЕФОННАР АША АЛА АЛАСЫЗ:

Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча дәүләт инспекциясе

www.gosalcogol.tatarstan.ru
www.tatzpp.ru

Территориаль органы	Телефон
Әлмәт территориаль органы	(8553) 33-67-02
Арча территориаль органы	(84366) 3-28-93
Яшел Үзән территориаль органы	(84371) 4-58-78
Казан территориаль органы	(843) 277-94-96
Яр Чаллы территориаль органы	(8552) 71-43-03
Түбән Кама территориаль органы	(8555) 36-63-76
Чистай территориаль органы	(84342) 5-49-85

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «кайнар линия» телефоны:

(843) 236-94-11

«ВКонтакте» да онлайн-консультация»:
www.vk.com/zpprpnrt

«Кулланучылар хокукларын яклау.
Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор»:
www.16.rospotrebnadzor.ru

«Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» ССФБУның консультация үзәге:

(843) 221-90-16 **www.fbuz16.ru**

Игътибар! Сез кулланучылар хокукларын бозу турында гаризаны Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенә тапшыра яки Татарстан Республикасының күп функцияле үзәкләре аша skype буенча кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча консультация ала аласыз.

6+

© ООО «ФОЛИАНТ», 2021 г.
Тираж 7000 экз. Заказ № 31/43
Отпечатано ООО «ФОЛИАНТ». 420111 г. Казань, ул. Профсоюзная, 17в
e-mail: foliantkazan@mail.ru



ҖИҺАЗ САТЫП АЛУЧЫЛАР ӨЧЕН БЕЛЕШМӘЛЕК

КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Татарстан Республикасында 2014-2025 елларда кулланучылар хокукларын яклау комплексы системасын үстерү подпрограммасын үтәү кысаларында, Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясенең заказы буенча әзерләнде

на татарском языке

Җиһаз сатканда кулланучы һәм сатучы арасында хокукый мөнәсәбәтләр, нигездә, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 07.02.1992 елның 2300-1 номерлы РФ Законы (алга таба – Закон) таләпләре һәм «Ваклап сату-алу шартнамәсе буенча товарлар сату кагыйдәләренә, кулланучының мондый товарны ремонтлау яки алыштыру чорында шушы ук төп куллану үзенчәлекләренә ия булган товарны түләүсез бирү турында таләбе кагылмый торган озак файдаланудагы товарлар исемлегенә һәм шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2020 елның 31 декабрендәге 2463 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр (алга таба – Кагыйдәләр) белән җайга салына.

Закон нигезендә, сатучы (башкаручы) кулланучыга товарлар турында кирәкле һәм дөрес мәгълүматны үз вакытында бирергә тиеш.

МӘГЪЛҮМАТ МӘҖБҮРИ РӘВЕШТӘ ҮЗ ЭЧЕНӘ ТҮБӘНДӘГЕЛӘРНЕ АЛЫРГА ТИЕШ:

- товарның атамасы;
- товарның фирма атамасы һәм урнашу урыны, сатып алучылардан претензияләр кабул итү өчен җитештерүче (сатучы) тарафыннан вәкаләтле оешманың урнашу урыны;
- товарның мәҗбүри таләпләренә туры килергә тиешле стандартларны билгеләү;
- товарның төп куллану үзенчәлекләре турында мәгълүмат;
- товарны нәтиҗәле һәм куркынычсыз куллану кагыйдәләре һәм шартлары (инструкция);
- җитештерүче тарафыннан конкрет товар өчен билгеләнгән очракта, гарантия срогы;
- билгеле бер чордан соң товарның үзе яки аның комплектлау өлешләре кулланучының тормышы, сәламәтлеге өчен куркыныч тудырырга, аның мөлкәтенә яки әйләнә-тирә мохиткә зыян китерә мөмкин булган очракта, хезмәт итү вакыты;
- товарның бәясе һәм сатып алу шартлары;
- кулланучы сатып алган товар элек кулланылышта булса яки анда җитешсезлекләр бетерелгән булса (җитешсезлекләр ачыкланса), сатып алучыга бу хакта мәгълүмат бирелергә тиеш;
- сатучы товарда булган җитешсезлекләр турында сатып алучыны телдән генә түгел, язмача да (товарның ярлыгында, товар чегында яки башка ысул белән) кисәтергә тиеш;
- функциональ билгеләнеше турында мәгълүмат;
- җиһазны әзерләгәндә һәм аны бизәкләгәндә кулланылган материаллар турында мәгълүмат;
- товарны сатып алучыга җиткерү һәм тапшыру ысуллары, сроклары, шартлары турында белешмәләр.

Товар турында мәгълүмат кулланучыларга җиһаз белән бергә бирелә торган документларда, товарларның аерым төрләре өчен кабул ителгән этикеткаларда, маркировкада яки башка ысул белән җиткерелә.

Кагыйдәләрнең 65 һәм 66 пунктлары нигезендә, әгәр якларның килешүендә башкача билгеләнмәгән булса, җиһазны җыю аерым түләү буенча башкарыла.

Әгәр дә касса чегы, мондый товарга түләүне раслаучы электрон яки башка документта товарның һәм сатучының исеме, артикул һәм (яки) модель, җиһаз җыелмасына (гарнитурына) керүче предметлар саны, кирәкле фурнитура саны, һәр предметның бәясе, җиһаз җыелмасының гомуми бәясе, тышлау материалы төре күрсәтелмәсә, товар белән бергә, кулланучы таләбе буенча, әлеге мәгълүматлар күрсәтелгән товар чегы бирелә һәм товарны сатуны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзалана.

ИГЪТИБАР!

Тиешле сыйфатлы җиһазлар гарнитурлары алмаштырылырга яки кире кайтарылырга тиеш түгел!

Җиһазларны ремонтлау яки аны алыштыру чорында шундый ук товарны бушлай бирү турында сатып алучының таләбе кагылмый.

ҖИҺАЗДА ҖИТЕШСЕЗЛЕКЛӘР АЧЫКЛАНСА

Законның 18 статьясы нигезендә, товарда кимчелекләр ачыкланган очракта (әгәр алар сатучы тарафыннан әйтелмәгән булса), кулланучы үз теләге белән сатучыга түбәндәге таләпләрнең берсен куярга хокуклы:

- шул ук маркадагы товарга (шул ук модель һәм (яки) артикул) алыштыру;
- сатып алу бәясен яңадан исәпләү белән башка маркадагы (модель, артикул) товарга алыштыру;
- сатып алу бәясен киметү;
- кичекмәстән товарның җитешсезлекләрен юкка чыгару яисә кулланучы, яки өченче зат тарафыннан аларны төзәтүгә тотылган чыгымнарны түләү;
- товар өчен түләнгән акчаларны кире кайтарып, сату-алу килешүен өзү.

Гомуми кагыйдә нигезендә, җитешсезлекләр гарантия срогы дәвамында ачыкланса, әлеге